Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авылы җирлегенең Сабанчы авылы
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карар

22 ноябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Сабанчы авыл җирлегендә гражданнар җыены йомгаклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21 ноябрендәге хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Сабанчы авылында гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Сабанчы авылында 2021 елның 21 ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәсе - гамәлдә дип танырга.

2. «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авылы җирлеге Сабанчы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: урам утларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү очен түләү, техник күзәтү үткәрү?» соравы буенча карар кабул ителмәгән дип танырга.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Сабанчы авылы, Яббаров урамы, 1 йорт адресы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.Д. Нурзаринов